СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.05.2024 г. Агрыз № 37-6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 03.04.2019 елның 36-3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мактаулы гражданы» исемен бирү турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 03.04.2019 елның 36-3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мактаулы гражданы» исемен бирү турында нигезләмәгә, 15 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Мактаулы гражданин" исеме булган гражданнарга айлык түләүләр турында мәгълүмат "Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа" дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев